**Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы**
**дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 256-29 «14» декабрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 22 августындагы 202-30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмә хакында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 22 августындагы 202-30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмә хакында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекнең 3.10 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.10. Муниципаль милек реестрын алып бара, муниципаль казнаны төзи.».

1.2. түбәндәге эчтәлекле 4.10 пункт өстәргә:

«4.10. тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен Азнакай муниципаль районының башка муниципаль берәмлекләреннән, килешү буенча тәэмин итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин